**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар башлануы турында хәбәр итү**

**1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре"** муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты (алга таба – проект) буенча ачык тыңлаулар башлануы хакында әлеге хәбәр белән хәбәр итәбез.

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- Территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә (1 Том);

- Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы (2 Том);

- Торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелеп килүче торак пунктлар чикләре) картасы (2 Том);

- Функциональ зоналар картасы (2 Том);

- Генераль планны нигезләү буенча материаллар. Әйләнә-тирә мохитне саклау. Аңлатма язуы (3 Том);

- Җирлек территориясеннән заманча файдалану картасы (4 Том);

- Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (гамәлдәге нигезләмә) (4 Том);

- Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект тәкъдиме) (4 Том);

- Инженерлык инфраструктурасы картасы (4 Том);

- Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, Гражданнар оборонасы чаралары картасы (4 Том).

**3. Проект буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча ачык тыңлаулар 2026 еклның 14 июленнән 2026 елның 10 августына кадәр үткәрелә. Ачык тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

- проект экспозицияләрен үткәрүгә проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны урнаштыру;

- ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;

- ачык тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Ачык тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча ачык тыңлауларда катнашучылар булып тора:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

**5. Ачык тыңлаулар уздырыла торган территория:**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге.

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

1) 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Совет мәйданы, 27 й.;

2) 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Совет мәйданы, 25 й.;

3) 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Һ. Такташ ур., 58 й.;

4) 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Кленовая ур., 4 й.;

5) 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча ш., Банк ур., 2А й.

**7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:**

2026 елның 21 июленнән 2026 елның 10 августына кадәр.

**8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**

Эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр. төшке ашка тәнәфес – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Ачык тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше**:

2026 елның 21 июленнән 2026 елның 10 августына кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган ачык тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язма яисә телдән;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының ачык тыңлауларын оештыручыга язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә түбәндәге адрес буенча: 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча

шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, тел. (84366) 3-12-44 (8.00 дән 17.00 гә кадәр), e-mail: lnur.Has@tatar.ru.

- Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12нче йортта (8.00 дән 17.00 гә кадәр) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язып кую юлы белән.

РФ Шәһәр төзелеше кодесының 5 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча ачык тыңлауларны 2026 елның 10 августында үткәрергә.

- 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитетында.

**11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат** порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
җитәкчесе Л.И.Абдуллин